**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от 29.04.2020** **№ 370**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләренә 2019 елның 1 гыйнвареннән 31 декабренә кадәр хисап чорына керемнәре, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында**

Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 17 апрелендәге 272 нче номерлы «2019 елның 1 январеннән 31 декабренә кадәр керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында» Указы, Татарстан Республикасы Президентының 2020 елның 24 апрелендәге ПУ-250 номерлы «2019 елның 1 январеннән 31 декабренә кадәр хисап чорында керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында» Указы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 14 мартындагы 662 нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы мунципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат, һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәр, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турындагы Нигезләмәдә билгеләнгән керемнәре, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләренә 2019 елның 1 январеннән 31 декабренә кадәрге хисап чорына белешмәләрне тапшыру срогын 2020 елның 1 августына кадәр озайтырга.

2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районы рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар аның рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин